КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 26 декабрь г.Казань № 1213

2025 – 2030 елларга Татарстан Республикасында «Актив озак яшәү» республика программасын (комплекслы планны) раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2024 елның 15 июлендә үткәрелгән «Гаилә» илкүләм проекты буенча стратегик сессиясе йомгаклары нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте Рәисе М.В.Мишустинның 2024 елның 6 августындагы ММ-П45-25475 номерлы йөкләмәләр исемлегенең 10 пунктын үтәү йөзеннән һәм «Гаилә» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проектын гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:
2025 – 2030 елларга Татарстан Республикасында «Актив озак яшәү» республика программасын (комплекслы планны) (алга таба – Программа);
2025 – 2030 елларга Татарстан Республикасында «Актив озак яшәү» республика программасы (комплекслы план) чараларын;
2025 – 2030 елларга Татарстан Республикасында «Актив озак яшәү» республика программасының (комплекслы планның) үтәлеше турында хисап формасын.
2. Программаны гамәлгә ашыру өчен җаваплы республика башкарма хакимият органнарына:
тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында каралган акча чикләрендә Программа чараларының үтәлешен һәм Программада каралган индикаторларга ирешүне тәэмин итәргә;
квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 1енә кадәр, әлеге карарның 1 пунктында расланган форма буенча Программаның үтәлеше турындагы хисапны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына кертергә.

Татарстан Республикасы дәүләт программаларын эшләгәндә Программада каралган чараларны исәпкә алырга.

3. Федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына, шулай ук әлеге Программада күрсәтелгән иҗтимагый оешмаларга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

Программа чараларын гамәлгә ашыруда катнашуны;

квартал саен, хисап кварталыннан соң килә торган айның 1енә кадәр, әлеге карарның 1 пунктында расланган форма буенча Программаның үтәлеше турындагы хисапны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына кертүне.

4. Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына 2025 – 2030 елларга өлкән буын гражданнарының актив озак яшәве буенча чараларның муниципаль программаларын (планнарын) эшләүне һәм раслауны тәкъдим итәргә.

5. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгына ай саен һәм квартал саен, хисап аеннан соң килә торган айның 1енә кадәр, ел саен – хисап елыннан соң килә торган елның 12сеннән да соңга калмыйча, «Гаилә» илкүләм проектының «Өлкән буын» федераль проектының «Актив озак яшәү» төбәк программасына җәлеп ителгән өлкән буын гражданнары өлеше» максатчан күрсәткечен исәпләп чыгару өчен Программага җәлеп ителгән өлкән буын гражданнары саны турындагы белешмәләрне Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына кертергә.

6. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына:

республика башкарма хакимият органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль районнарының һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнары, Программада күрсәтелгән иҗтимагый оешмалар тарафыннан кертелә торган мәгълүматны җыюны гамәлгә ашырырга һәм квартал саен (хисап аеннан соң килә торган айның 10ысына кадәр) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына гомумиләштерелгән мәгълүматны кертергә;

әлеге карарның 5 пункты нигезендә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан тапшырыла торган мәгълүматларга таянып, «Гаилә» илкүләм проектының «Актив озак яшәү» төбәк программаларына җәлеп ителгән өлкән буын гражданнары өлеше» максатчан күрсәткечен исәпләүне тәэмин итәргә, ай саен һәм квартал саен, хисап аеннан соң килә торган айның 3есенә кадәр, ел саен, хисап елыннан соң килә торган айның 15еннән дә соңга калмыйча, Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының программа-мәгълүмат комплексында хисап чоры өчен Татарстан Республикасы буенча ирешелгән күрсәткечне урнаштырырга.

7. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 26 август, б-2071 нче; 2021 ел, 27 ноябрь, б-2461 нче; 2022 ел, 12 гыйнвар, б-12 нче; 2023 ел, 21 март, б-692 нче; 2023 ел, 11 сентябрь, б-2028 нче; 2023 ел, 30 декабрь, б-3275 нче боерыклары үз көчен югалткан дип танырга.

8. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин